ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 1 пунктында «социаль куркыныч хәлдә» сүзләреннән соң «, шул исәптән гаиләдә рәхимсез мөнәсәбәткә дучар ителгән,» сүзләрен өстәргә;

2) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе» сүзләрен «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 өлештә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе» сүзләрен «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 25 декабрь
№ 113-ТРЗ